# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«26» сентябрь 2022 ел № 407

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 28 октябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Белоус авылында Үзәк урамы буенча 16 йорт янында Белоус авылының Үзәк ур., Лесная ур., Прикамская ур., Лесной тыкрыгы, Лесхимучасток, Полянский участогы, Травянка Хуторы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 28 октябренә 19.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Белоус авылында Солнечная урамы буенча 37 йорт янында Белоус авылының Сосновая ур., Солнечная ур., Р.Беляев ур., Парковая ур. буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2022 елның 28 октябренә 20.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Белоус авылында Дачная урамы буенча 1 йорт янында Белоус авылының Дачная ур., Пихтовая ур..

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Белоус авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 2000 (ике мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) тротуарны төзекләндерү;

2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

6. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга: Белоус авылында старостаны сайлау.

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов